БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 11 2020 ел № 322

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2008 елның 23 маендагы карары белән расланган ««Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт өчен субсидияләр бирү турында» Нигезләмәгә (2020 елның 16 октяберендәге 302 номерлы үзгәрешләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Муниципаль торак фондының күпфатирлы торак йортлары белән идарә итү өчен шартлар тудыру максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2008 елның 23 маендагы 197 номерлы карары белән расланган ««Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт өчен субсидияләр бирү турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекне «3. Күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт ясау эшләрен башкару өчен подряд оешмаларын сайлап алу тәртибе» түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

« - субсидия алучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш.».

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов